# ИҢ ЯХШЫ КИТАПЛАР — БАЛАЛАРГА

**Шәһәрдәшебез шагыйрә Вера Хәмидуллина проекты буенча бакча яшендәге балалар өчен китаплар нәшер ителүе белән хәбәрдар булсам да, бу фидакарь ханымның аларны үз акчасына чыгаруын белми идем.**



дөнья күргән. Шуларның икесе дүрт телдә — рус, татар, инглиз (Булат Хәйретдинов тәрҗемәсе) һәм немец (Раиса Шиллимат) телендә нәшер ителгән. "Сад" сериясен рәссам Ольга Недовизий бизи. Балалар китапларына классикларның әсәрләрен түгел, заманча авторларныкын алуны максат иткәннәр. Аларда Татарстан әдипләре Рәшит Бәшәр, Факил Сафин, Зиннур Мансуров, Галимҗан Гыйльманов, Әлфия Ситдыйкова, Зөләйха Минһаҗева, Идельбикә, Сергей Карпеев, Борис Вайнер һ.б. белән бергә Россиядә, ерак һәм якын чит илләрдә яшәүче авторлар Светлана Савицкая, Александр Тимофеевский, Софья Прокофьева, Зинаида Кокорина, Валентина Черняева, Татьяна Окоменюк әсәрләре урын алган.

Киләчәктә Татарстаннан бик күп авторлар әлеге проектта катнашырга теләк белдерәләр: Сергей Малышев, Лилия Газизова, Рафис Корбан, Равил Фәйзуллин, Газинур Морат, Роберт Миңнуллин... Рөстәм Кутуйның хатыны иренең шигырьләрен биргән.

Россия, Татарстан, XXI гасыр Язучылар берлекләре әгъзасы, "Татарстан. Аргамак" әдәби альманахының баш редактор урынбасары Вера Хәмидуллина проект авторы буларак, "Идел-Пресс"та басылган китапларның сыйфатыннан канәгать: эшләнеше яхшы, буяулары бик матур, ачык, шрифтлар балалар китабына туры килә торган, ди.

Китапларны нәшер итү кызу темплар белән барса да, киләчәктә финанслау мәсьәләсе хәл ителмәсә, проектның тукталуы ихтимал. Дөрес, Мәгариф министрлыгы да хуплаган аны. Бу сериядәге китапларны чыгаруны 2014-2023 елларда ТР дәүләт телләрне үстерү программасына кертү турында хат та алганнар. Шушы көннәрдә бу фидакарь ханымнар ТР Мәдәният министрлыгына барырга җыеналар.

ТР Дәүләт Советының фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе Разил Вәлиев бу серия китаплар белән хөкүмәт җитәкчеләрен таныштырырга вәгъдә иткән.

Проект бюджеттан финансланган очракта аларның тиражларын арттыру да мөмкин булыр иде. Әлегә алар бер мең данә тираж белән генә нәшер ителә.

Шул сәбәпле, проектта катнашучыларның күбесенә коры энтузиазмда гына эшләргә туры килә. Әзер басманы сатудан кергән акча икенче китапны чыгаруга тотыла. Финанслау җайга салынып, эшләүчеләргә хезмәтләре өчен түләү мөмкинлеге туса, исәпләре — техник хезмәткәрләр алу. Чөнки әлегә шушы ике ханым корректор да, техник редактор да — үзләре. Китапларны алып кайту, төяү-бушату, сату да алар өстендә. Атнасына ике тапкыр Казанга барырга туры килүен дә исәпкә алсаң, иҗат белән шөгыльләнергә вакытлары бик аз кала аларның. Ләкин зарланып зарлары юк, киресенчә, дәртләнеп эшлиләр. "Вера белән танышу, бергәләп иҗат итүебез үзе үк миңа яңа көч өстәде. Әлеге проектта катнашу минем иҗатымны баета. Легендар шәхесләр белән очрашу, аларның әсәрләрен тәрҗемә итү, балалар өчен эшләү — үз иҗатыма да рухи азык бирә", — ди Әлфия Мирзануровна.

Ә иң мөһиме, китаплар үз укучыларын тапкан — аларны балалар яратып укый, көтеп ала. Бөтендөнья татар конгрессы, ТР Язучылар берлеге, республика балалар китапханәсе басмаларга яхшы бәя биргән. "Рәссамнарыбыз гран-прига, тәрҗемәчеләребез Әлфия Ситдыйкова һәм Факил Сафин Россия язучылар берлеге һәм Россия тәрҗемәчеләр берлегенең Грибоедов исемендәге истәлек медаленә, Маяковский орденына лаек булды", — ди Вера ханым. Шушы көннәрдә генә "Садик" проекты Берлинда үткән "Лучшая книга 2013 года" халыкара конкурсында җиңү яулады. Вера Хәмидуллина — "Елның иң яхшы нәшире", Факил Сафин һәм Әлфия Ситдыйкова "Переводческий олимп" бүләкләренә лаек булды.

Бу фидакарьләр нәшер иткән китаплар инде дөньяның байтак илләренә — Мадридка рус теле үзегенә, Болгария илчелегенә, Һиндстанга, Австралиягә, Израильгә киткән. Әле күптән түгел генә "Зеленая планета" Россия экологик хәрәкәтенең ун еллыгына багышланган форумда катнашучыларны котлап, Мәскәүгә 400 китап җибәргәннәр. Үткән атнада шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сараена Александр Тимофеевский белән очрашуга килгән балаларга да әлеге чараның иганәчеләре китапларны бүләк итеп таратканнар.

Әлегә әзер китапларны кибетләрдә сату мөмкинлеге юк, чөнки проектны эшләүчеләрнең сатудан акча кергәнен көтәргә вакытлары юк. Нигездә китапханәләр заказы буенча эшлиләр. Китапларны 23/10 б йортында урнашкан офистан ("Экспресс-тур" фирмасы) сатып алырга мөмкин. Һәр китапта мөрәҗәгать итү өчен электрон адрес та күрсәтелә.

Балаларын рус һәм татар телләрендә иркен аралашучы, чит телләрне белгән зыялы шәхесләр итеп үстерергә теләгән әти-әниләр өчен "Садик" һәм "Сад" сериясе китаплары — чын мәгънәсендә хәзинә ул.

**Илгизә ЛОТФУЛЛИНА.**
**Автор фотолары.**